МӘГАРИФ

АЙЛЫК ИҖТИМАГЫЙ-ПЕДАГОГИК һӘМ ФӘННИ-ӘДӘБИ ЖУРНАЛ

О Е Ш Т Ы Р У Ч Ы Л А Р: ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХӨКҮМӘТЕ, ХАЛЫК МӘГАРИФЕ МИНИСТРЛЫГЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

№ 12 (682) ДЕКАБРЬ | 1918 елның ноябреннән чыга | Татар телендә


Баш мөхәррир
Фәрит ШӘРИФУЛЛИН

Редколлегия

Румин АКБАШЕВ,
Мәҗит ВӘЛИУЛЛИН
баш мөхәррир урынбасары),
Тихния ГАЙФУЛЛИНА,
Миркасыйм ГОСМАНОВ,
Рәшит ИСЛАМШИН,
Зөфәр МИФТАХОВ,
Гайнан МӨХӘММӘТҖАН
җаваплы сәркатип),
Айдар САФИН,
Роза СЫРОМОЛОТОВА,
Фарис ХАРИСОВ,
Рамил ХӘЛИУЛЛИН,
Камәрия ХӘМИДУЛЛИНА,
Рүзәл ЮСУПОВ,
Фәүзия ЮСУПОВА,
Фәрит ЮСУПОВ,
Миңнехан ӘХМӘТҖАНОВ.

Бүлек мөхәррирләре:
Э М. ЛАТЫЙПОВ (туган тел һәм әдәбият, төрле фәннәр).
М ШӘФИГУЛЛИНА (рус теле һәм әдәбияты, мәктәпкәчә тәрбия).
Гыйльми мөхәррир: (физика, математика, башлангыч мәктәп).
Мөхәррир:
М Х. ВӘЛИЕВ (педагогика-методика, мәктәп һәм гаилә).
Бизәлеш мөхәррире:
Д Ә МОРГАЦКАЯ

Телефоннар:
Баш мөхәррир 53-57-35
Баш мөхәррир урынбасары 53-39-15
Җаваплы сәркатип 53-07-82
Бүлек мөхәррирләре 53-07-80
53-07-78



**Хатлар өчен адрес:**
420066, Казань,
ул Декабристов, 2.
Редакция журнала
«Мәгариф», а/я 47

© «Мәгариф», 1992 ел.

# БУ САНДА

## АҢ БЕЛЕМ ВӘ ЭШ-ГАМӘЛ

Тарихыбызда Татарстан мәнфәгатьләрен күздә тоткан беренче Конституция (Конституция кабул итү уңаеннан 1992 елның 6 ноябрендә Татарстан Республикасы Югары Советы сессиясендә Президент М. Шәймиев чыгышы) 2
**Исмәгыйлева С., Исмәгыйлева Ф.**— Тәрбия хәзинәләре 4
**Әхмәтҗанов М.**— Халык традицияләре 7
**Сидорова Г.**— Базар мөнәсәбәтләре таләбе 9
Даһи галим (Н. И. Лобачевскийның тууына 200 ел) 11
Осталыкка конкурс йомгаклары 12

## БАШЛАНГЫЧ КЛАСС

**Мостафина Р.**— Фәннәрне берләштереп укыту (Дәвамы) 13
**Фәйзрахманова К., Хәмзин А.**— Без — кояш балалары (Шаян сәхнә) 16

## ТУГАН ТЕЛ һӘМ ӘДӘБИЯТ

**Мәҗитова Р.**— Әдәбият дәресләре һәм... сәнгать 19
**Билалова Ә.**— Лексика дөньясына сәяхәт 22
**Поварисов С.**— Сүз эчендә энҗе бар 24
**Гыйлаҗев И.**— VI класс. Тематик планлаштыру 25
**Рәфыйкова Г.**— Татар теле көннәре 27
Хат китерә тормыш сулышын 29

## РУС БАЛАЛАРЫНА ТАТАР ТЕЛЕ УКЫТУ

**Юсупов Ф., Казиханова З., Мөхиярова Р.**— II класс (Дәвамы) 30

## РУССКОЕ СЛОВО

**Шакирова Д., Абранина А.**— Детектив и школа 33
**Бакеева М.**— Антонимы и выразительность речи 36
**Андреев П.**— Урок-суд над жестокостью и безнравственностью 38
**Хасянова Н., Ахбарова Г.**— Кружок выразительного чтения 41
**Скиргайло Т.**— Деловые бумаги — в развитии речи 43

## КУЛЬТУРА И ИСТОРИЯ ТАТАРСТАНА

**Каримуллин А.**— У истоков татарской книги 46
**Гарифьянова Р.**— Фундаментальное исследование 47

## МӘКТӘПКӘЧӘ ТӘРБИЯ

**Салихова Д.**— Абруйлы Гүзәл, сүлпән Алмаз... 48

## СЕЗГӘ, ӘТИ-ӘНИЛӘР, МӘГАЛЛИМНӘР

**Газиев Ә.**— Психогимнастика: хисләр һәм хәрәкәт 50
**Камалов Б.**— Хатын-кызлар хакын хаклау (Дәвамы) 51
**Баязитова Ф.**— Туйда үзара бүләкләшүләр 53
**Биочинская Л.**— *Яман авырудан сакла244йк* 55
Сабыйларга укыгыз 56
**Әхмәрев Г.**— Казан тарихы 57
1992 елда басылган мәкаләләр исемлеге 59
**Сезгә кирәкле китаплар** 62
**Безнең календарь** 63
**Ял сәгатьләрендә** 64

# ТӘРБИЯ ХӘЗИНӘЛӘРЕ*

**Алтыдагы — алтмышка**

**(Икенче әңгәмә)**

**... Саф әле күңелең синең, һичбер бозык уй кермәгән,**
**Пакь телең дә һич яраусыз сүзләр әйтеп күрмәгән.**
**Пакь җаның һәм пакь тәнең — барлык вөҗүдең пакь синең;**
**Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!..**

**(Г. Тукай. «Таян аллага».)**

Әнә нинди саф ул сабый бала! Кеше булсын өчен, ата-анасына, милләтенә, иленә таяныч булып үссен өчен, дөньяга килүе белән, аны тәрбияләү, акылын-фигылен, зиһенен үстерү башлана.

Тууыннан алып беренче адымнарын атлап киткәнгә кадәр халыкның балага биргән тәгълим-тәрбиясе нидән гыйбарәт булган соң?

Борын-борыннан ук билгеле, тәрбия бала туганчы ук башлана. Бала туып, бераз үсә төшкәч, аның үз-үзен тотышындагы кимчелекләр (көйсезлек, киреләк), аннары исә үзсүзлелек, тотнаксызлык, елаклык, киреләннән артык иркәлек, сүз күтәрмәү, сүзендә тормау, хыянәтчеллек кебек сыйфатлар — барысы да начар тәрбия нәтиҗәсе.

Шул ук вакытта, гаиләдә бала туу — гаять зур шатлык булып саналган. Бу уңайдан бик матур гореф-гадәтләр барлыкка килгән: бәби кабул итү; киндек әбисенә хөрмәт күрсәтү; бәби туе уздыру; балага тирән эчтәлекле һәм матур яңгырашлы, милли рухка ятышлы исем кушу; аны имезү, юындыру; кәефен, йокысын яхшыртуның бөтен чараларын күрү; һәр җирдә чисталык булдыру, изге теләкләр теләү, ягымлы сүзләр әйтү, сәламәтлеге ныгыганчы, ананы карау; ана һәм яңа туган бала өчен мунча ягу һ. б. Бәби туган йортка кенәзын аяк эзе өзелми. Күрше-күлән, туган-тумача һәм дус-ишләр ананың һәм бәбинең хәлен белергә килә, кулыннан килгән ярдәм күрсәтә.

Баланың беренче көненнән үк туплый башлаган хәзинәсе — аның туган теле. Әни. Әти. Бабай. Әби. Мәми. Ипи. Сөт. Чәй. Аш. «Әлли-бәлли» — йокларга вакыт җиткән. «Тәти» — матур, кирәкле нәрсә! Гөл — нинди матурлык! Матурлыкка, яхшылыкка, начарлыкка да сабый авазлар белән бәя бирергә өйрәнә. Өлкәннәр балага карата зур саклык, сабырлык, зирәклек күрсәтәләр. Өйдә бер-береңә карата дорфалыкка, тупаслыкка юл куелмый. Киресенчә, балада уңай тойгылар булдыру чаралары күреләр: ягымлы йөз, иркә сүзләр, вакытында ашату, кулда имезү, җылы куенга алып юату. Монда ананың ягымлы тавыш белән әйтелгән теләкләрә, сабый белән аңа гына хас һәм шул ук вакытта башкаларга да аңлаешлы сүз-серләр. Туган тел аша сабыйда газиз әнкәсенә, әтисенә, әби-бабасына, туганнарына, туган туфрагына, туган як табигатенә хөрмәт, аны белергә, төшенергә омтылу тәрбияләнә.

Безнең әби-бабаларыбыз, тел һәм әдәбият гыйлемен белмәсәләр дә, бала сөйләмендә читят сүзләр буталып йөргәнне яратмаган, саф татарча сөйләшүне таләп иткән. Халык өчен бу, гомумән, катгый кагыйдә булган.

Татар зыялылары заманында төрек, гарәп, фарсы телләрендә дә иркен сөйләшкәннәр. Бу хәл укымышлылыкның мөһим күрсәткече булып саналса да, гади халык өчен ят булган. Мәдрәсәдә чит телләр өйрәнәсең икән — рәхим ит, белемеңне арттыр, зиһенеңне үстер, галим бул. Бер тел — бер ачкыч, ике тел — ике ачкыч. Йөргән җирендә юллар такыр булуга сәбәп булыр. Рус телен дә өйрәнү кирәк — иңгә-иң яшибез үзләре белән. Ләкин өеңдә, кардәш-ыру, күрше-күлән, авылдашларың белән үз телеңдә сөйләш, хәлеңнән килгән кадәр милләтеңә хезмәт ит, аны алга әйдә.

Менә нинди язылмаган законнарын гамәлгә керткән халык үзенең укымышлы ул һәм кызлары яшеешендә. Үз баласының нинди шартларда зиһенле, белемгә хирыс, гаилә җанлы, кешелекле, мәгърифәтле булып үсесен үз тәҗрибәсендә, үз җилкәсендә һәм үз йөрәге аша ачыклаган халык. Иң беренче чиратта, әлбәттә, дөньяда иң гүзәл, иң мәрхәмәтле ана йөзе аша. Беренче сүзләр дә — анага: «әни», «әнnә», «мәммә». Балага карата да кояштай балкып торган ана сүзләре: «бәбкәм», «иркәм», «гөлкәем», «айгынам», «йолдызым», «батырым» (ир балага), «күгәрченем», «күз нурым»...

*Әлли-бәлли бәүкәем,*
*Җан йөрәгем, нәнкәем,*
*Рәхәт кенә тынычлап,*
*Йоклап китәр бәбкәем.*

Дүрт юлда дүрт яратып-назлап эндәшү.

Әби яки башка кеше караса да, **баланы тынычландыру ана исеменнән алып барыла**.

*Әлли-бәлли күз нурым,*
*Сандугачым, былбылым,*
*Әниең кайткач, тук булырсың,*
*Сабыр итеп тор, улым.*

Ана әйтә икән, ана кайтачак икән — бу инде шатлык: бала елмая, кулларын чәбәкли, изрәп йокыга китә.

Тора-бара танып-белү офыгы киңәя: әти, әби, бабай, апа, абый. Бала, гадәттә, үз кешеләренә елмая, чит кешегә төбәгән күз карашы кырыс була. Тагын ата-ана ярдәмгә килә «Бу — апа, Мәдинә апа, күрше апа ул, тәти апа». Алай икән — кәтелгән елмаю, димәк, күрше апаны үзенә якын итеп кабул итү.

Туган телгә, иксез-чиксез дөнья киңлегенә алып керә торган бәя бирәп бетермәслек әһәмиятле чыганак — **бишек җырлары.** Аларның иҗатчылары — әниләр, әбиләр, бала караучы үсмерләр, шулай ук шагыйрьләр. Мәсәлән, Дәрдмәнд, Тукай да бишек җырлары иҗат иткән. Алар аша сабый тәүге мәртәбә матурлык, ананың йөрәк җылысы, ата-ана мәхәббәте, үз халкының рухы, *аһәңле теле белән*, туган йорт, туган тел, туган туфрак, ага-энә, чишмә суы кебек төшенчәләр белән очраша. Һәрьяклап ярдәмгә мохтаҗ һәм әлегә бик тә зәгыйфь сабый бишек җырларының сүзләреннән һәм көенннән үзенә тәм һәм ямь, тәненә һәм җанына ләззәтләнү, ял таба. Ул, бишек янында иң саф хисләре, кайгы-шатлыклары, уй-хыяллары белән уртаклашкан әнисенең хәленә кергәндәй, аның теләкләрен аңлагандай була. Җырлардан ул үз

* Дәвамы. Башы журналның быелгы 10 нчы санында

халкының мәгърифәтне яратуын, һәркемнең үз баласын укытырга тырышуын сиземләп үсә.

Кыз баланың чибәр, зифа буйлы, акыллы, йөз кешә арасыннан бер генә кешегә насыйп булып, ир баланың батыр, кыю, якыннарына таяныч булып үсүләрен теләү исә балада белә-үдә чактан ук әхлаклылык сыйфатлары, җаваплылык хисләре тәрбияли башлау дип аңлашыла.

Бала үскән саен, тәрбия чараларының төрләре үзгәрә. Такмак һәм такмазалар әйтеп уяту, үчти-үчти сикертү, тез һәм аяклар өстендә сикертү, тәпи йөрергә, биергә өйрәтү, мунча кертү, юындыру, телен ачтыру, хәрәкәтләндерү, киенлдерү, сузылдыру. Болар барысы да сабыйларны, бердән, физик яктан чыныктыралар, икенчедән, аларны рухи яктан баеталар. Сөйләм ритмы белән хәрәкәт ритмы тәңгәл килү (бишек җыры кебек озын җыр җырланмый), иң матур өметләр белән сугарылган теләкләр, шатлыклы-куанычлы һәм аһәңле тавыш, шат-шаян йөз бөбиләрнең гармоник үсүе өчен иң уңай шартлар тудыра.

Мисал өчен баланы коендырганда әйтелә торган юаткычны китерик.

> Суы саркысын,
> Үзе калкысын,
> Тигез канатлы булсын,
> Озын гомерле булсын,
> Бәхетле, тәүфыйклы булсын,
> Игелекле, шәфкатьле булсын[1].

Бишек җырлары, юаткычлар, мавыктыргычлар балаларны үз поэзияләрен булдырырга, җырлы-биюле, такмаклы-такмазалы уеннарда (эндәшләр, үртәвечләр, алдавычлар, иярмешләр, әйтешләр, санамышлар, тел көрмәкләндергечләр, шобага әйтешләр h. б.) рәхәтләнеп катнашырга һәм камил табигатьле шәхес булып үсәргә, өлгерлеккә, зирәклеккә, яхшы хәтерлелеккә, уйлап табучанлыкка, гаделлеккә, матурлык дөньясына сукмак салып куя.

*Балалык еллары өчен гаҗәеп кызыклы, тылсымлы, гыйбрәтле тормыш дәреслеге бар.* Бу — **әкиятләр.** Аларга халыкның педагогик культурасы, милли үзаңы, әхлак сыйфатлары, күңел матурлыгы, нәфис зәвыгы тупланган. Һәр әкиятнең тәрбияви максаты бар: һәрберсе гыйбрәтле, үгет-нәсихәтле, нинди дә булса әхлакый хакыйкатьне үткәрә. Образлы, шул ук вакытта иң нечкәләргә дә аңлаешлы тел белән халык хезмәткә, тырышлыкка, күңел сафлыгына дан җырлый, югары әхлак сыйфатларын калку итеп күз алдына китереп бастыра, гаделлек һәм зирәклекне җиңүче итеп калдыра, ялкауларны, рәхимсезләрне, комсызларны, әдәпсезләрне көлке һәм мескен хәлләргә куя.

*Халык педагогикасын тудыруда башлангыч омтылышларның берсе буларак,* әкиятләр үзенчәлекле яклары белән аерылып торалар. Иң беренче чиратта бу — халыкчанлык, халыкка хас әхлак сыйфатларын гәүдәләндерү: туган илгә мәхәббәт һәм аны яклауга хәзерлек, явызлык белән аяусыз көрәш, хезмәт сөю һәм төрле һөнәрләрдә осталык, гаделлек, дус-ишләргә һәм вәгъдәгә тугрылык, иҗади активлык, табигатьне зурлау, аның серләренә төшенергә омтылу, хайваннар дөньясын яхшы белү... Болар барысы да халыкның характерын, психологиясен, яшәү рәвешен чагылдыра.

Әкиятләрдәге хыял, оста итеп уйлап чыгару балаларның иҗади фикерләвен үстерә. Тыңлаганда, сөйләгәндә, үз әкиятләрен тудырганда бала хыяллана, уйлап таба, үзенең эчке дөньясына якын образларны күзаллый һәм намуслылыкны, хезмәт сөюне, тырышлыкны, гаделлекне җиңүче итәргә омтыла.

Әкиятләр балаларда төрле хисләр тәрбияләү ягыннан да игътибарны җәлеп итә: күңеллелек, соклану, шатлык, көлү, ягымлылык, мөлаемлык, кайгырту, кызгану, нәфрәтләнү h. б.

Әкиятләр балаларга гына түгел, өлкәннәргә дә тәэсир итә. Бу җәһәттән К. Д. Ушинскийның сүзләре кызыклы: «Халык әкиятләре аша бала бөеклек һәм шигърият белән сугарыла. Халык балаларга үзенең татлы хыяллары турында сөйли һәм бу хыялларның яртысына үзе дә ышана»[2].

Әкиятләр, гадәттә, йокы алдыннан, төнлә сөйләнә. Бу — *гаҗәеп отышлы традиция.* Ул хәтта буыннарның рухи якынлыгы символына әверелеп китә: өлкәннәр кечерәкләргә аңлаешлы итеп, еллар буе тупланган, гасырлар дәвамында бөртекләп җыелган әхлакый һәм рухи кыйммәтләрне тапшыралар. Әкият гаиләне бергә туплау, үзара дуслаштыру, өлкәннәр һәм яшьләрнең үзара рухи якынлыгын тәэмин итү чарасына әверелеп китә. Әкиятләр сөйләү гадәткә кергән гаиләләрдә кешеләр үзара дус, бер-берсенә терәк-таяныч булып яшиләр.

Күренекле *әдипләребез, педагогларыбыз* гаиләдә әкиятләргә зур урын бирергә, аларны күпләп сөйләргә тәкъдим итәләр. «Бүгенге цивилизацияле фән-техника дәверендә,— дип яза Ч. Айтматов,— әкиятләргә вакыт та юк сыман. Әмма бу — әкиятне тормыш-көнкүрештән чыгарып ташларга мөмкин, дигән сүз түгел. Бу безнең тарафтан җибәрелгән мәгънәсезлек һәм кешелексезлек булыр иде. Үткәннең тәҗрибәсеннән йөз чөерергә ярамый. Әкият — кешелек тәҗрибәсе ул. Без әкиятләрне борынгы тәзелеш сәнгате истәлекләрен саклаган кебек үк сакларга тиешбез»[3]

Халык педагогикасында әкиятләр белән беррәттән дастаннар, легендалар, кыйссалар, бәетләр дә зур тәрбияви вазифа башкаралар, чөнки алар үткәнне генә түгел, бүгенгене һәм киләчәкне дә күрергә ярдәм итәләр. Татар халкының азатлык өчен көрәшен, тормыш-көнкүрешен, гореф-гадәтләрен, педагогик мирасын чагылдырган, хикәяләү рәвешендә язылган, милли үзенчәлекле әсәрләр гаиләдә тормыш дәреслеге вазифасын үтәрлек тәрбияви көчкә ия булып торалар.

Үсеп килүче яшь буынга тәгълим-тәрбия бирүдә халык бик үтемле итеп **мәкаль** һәм **әйтемнәрдән** файдаланган. Мәкаль һәм әйтемнәрнең тәрбияви эчтәлеге, аларның шигърият белән тыгыз бәйләнеше тормышның һәр очрагында телгә җиңел килеп, уй-фикерне матур яңгырашлы итеп әйтергә мөмкинлек бирә. Мәкаль һәм әйтемнәрдә сүзләр үзара тыгыз бәйләнгән. Алар, гадәттә, гыйбрәтле эчтәлекле булалар, халыкның уй-омтылышларын, иҗтимагый тормышка, тәрбия мәсьәләләренә мөнәсәбәтен билгеләрләр.

---

[1] **Ягъфәров Р.** Шигърият чишмәләре — Казан, Тат кит нәшр., 1935, 33 б

[2] **Ушинский К. Д.** Избр. пед соч. М , Учпедгиз, 1954, с 57.

[3] **Айтматов Ч.** Чипалак (Мизинец). «Пионерская правда», 1970, 10 март.

Мәкаль һәм әйтемнәр кыска, аз сүзле һәм тирән мәгънәле, үгет-нәсихәтле, тиз хәтердә калалар һәм ритмлы, көйле булганга, җиңел әйтеләләр. Күбесе әхлак кагыйдәләренә әверелеп киткән:

*Баланы бала арасында якласаң, әлекче булыр.*

Баланы эшкә өйрәт, эшен бетерергә өйрәт.

Бала үлгәнгә салынса, син аны күмгәнгә салын.

*Җидесендә ни булса, җитмешендә шул булыр.*

Сабыйга ат та ат, таяк та ат.

Сабый хөкеме — уен.

Теше чыккан балага чәйнәп биргән аш булмас.

Тәрбиясез бала хайван булып үсәр.

Ачы белән тәзәтәләр, татлы белән бозалар.

Сабый елый-елый үсәр.

**Табышмаклар** иҗат итеп тә, халык тәрбияви максатларны күздә тоткан дияргә була. Аларның төгәллеге, ятышлы ритмикасы һәм бертөрле аһәң белән әйтелеше, объектның асылын, исемен эзләп табу бурычы куелу, җавапның тиз арада табылырга тиешлеге, икеден дә ким булмаган катнашучылар күздә тотылу балаларда зирәклек, тапкырлык, фикерләү сәләтен, ялын мәгънәле итеп оештыру күнекмәләрен үстерә, сөйләмен камилләштерә. Гаҗәеп матур төзелгән бу әсәрләр балалар өчен эстетик ләззәт чыганагы да булып тора. Берничә мисал.

**Урманда урынсыз, кырда койрыксыз. (Җил.)**
**Кара мыеклы җизнәм сагындырып килгән. (Яз.)**
**Борынсыз чыпчык боз тишә. (Тамчы.)**
**Күктән килде, җиргә китте. (Яңгыр.)**
**Ак ашъяулык таптык, җир өстенә яптык. (Кар.)**
**Агач үгез, өч мөгез. (Сәнәк.)**
**Суда туды, җирдә үлде. (Балык.)**
**Әлем-әлем әлем күк,**
**Бөгәрләнгән мәче күк,**
**Аны кеше тоталмый,**
**Төпиләрен куралмый. (Керпе.)**

Өч — дүрт яшьлек балалар да һич тотлыкмыйча һәм бик яратып әйтә торган мондый табышмакларны халкыбыз иксез-чиксез санда иҗат иткән.

Югарыда санап кителгән чаралардан тыш, тәрбия, белем һәм күнекмәләрне балага әтиәни, әби-бабай һәм башка өлкәннәр (абый, апа, җиңги, җизни һ. б.) турыдан-туры гаиләдә, көндәлек эш, йорт мәшәкатьләре барышында күрсәтмәләр аша бирү гадәти күренеш булган.

Әйтик, бала үзен **табын янында** ничек тотарга тиеш? Моңа өйрәтү турыдан-туры табын хәстәре вакытында кыска-кыска күрсәтмәләр төсендә барган.

**— Кызым (улым), әти-әниден алда табын янына килеп утырма.**

**— Әти-әниден алда кашык тотып ашка сузылма.**

**— *Табын янында борыныңны тартма, чәмереп ашама.***

**— Аш алдыннан, аштан соң кулыңны ю, авызыңны чайка.**

**— Ипи валчыкларын коеп ашама, ипинең рәнҗеше төшәр.**

**— Ипи өстенә әйбер куйма, ипидән өстен нәрсә юк.**

**— Ипекәйнең валчыгы да бездән олы, коеп ашама.**

**— Ипи валчыгыңны җый, йорттан бәрәкәт очмасын.**

**— Ашны күрсәң, кадер тот, дусны күрсәң, гадел тот.**

**— Сыныгыңны ашап бетер, бәхетеңне калдырасың бит.**

**— Яманнан ярты кашык аш калыр.**

**— Ит иткә, шулпасы биткә.**

**— Чүлмәктән *ашама, кешеләр арасында* сүзең үтмәс.**

**— Пычак белән ашама, кешегә пычак булып кадалырсың.**

**— Як-ягыңа күп каранма, ризыксыз калырсың (ашыңны җен ашап китәр).**

**— Ашыгып ашама, ашаганың тәнеңә йокмас.**

**— Чөең чәмереп эчмә, ямьсез булып үсәрсең.**

**— Ашаганда киерелмә, үсми калырсың.**

**— Ашка рәхмәт әйт.**

**— Кеше пешергән ашны кашык тыгып болгатма.**

**— Тавышлы табыннан фәрештә качар.**

**— Күп ашасаң, бал да ачы була.**

**— Вакытында туя бел, кашыгыңны куя бел.**

**— *Өстәлне кәгазь белән сөртмә, тавыш чыгар.***

Минә бала әтисе, әнисе, я булмаса әбисе я бабасы белән **урам буйлап бара.** Анда да күрсәтмәләр, киңәшләр:

**— Олыларга үзең башлап сәлам бир.**

**— Өлкәннәргә юл бир.**

**— Алдыңны-артыңны карап йөр, эт килеп тешләмәсен (каз таламасын; корт килеп чакмасын; абынып егылырлык булмасын һ. б.).**

**— Сызгырып барма, янгын чыгар.**

**— *Коега тәкерме, суын эчәрсең.***

**— Юлдан ерак уйна.**

**— Урам үләнен йолкыма, үлән йолку фәрештә канатын сындыру бит ул.**

**Урманда, кырда:**

**— *Урман үстер, ачлык күрмәссең.***

**— Урманга шырпы белән бармыйлар.**

**— Агач үләме балтадан.**

**— Корт баскан черек ботакны кисмә.**

**— Суга тәкермә, үзең төшәрсең.**

**— Яшь агачны сындырма, яшь гомерең өзелер.**

**— Җимешен аша, ботагын сындырма.**

**— Урманга кергәнче чыгар юлыңны кара.**

**— Агачның тамырына балта чабып, киләчәгеңне караңгылатма.**

**— Агачның тамырына балта чапканчы киләчәгеңне уйла.**

**— Яшь үләндә арык мал да уйнаклый.**

**— Җимеш ашыйсың килсә, чәчәген өзмә.**

**— *Кошларны рәнҗетмә, каргарлар.***

**— Кошларга таш атма, күзең сукыраер.**

**— Бер дә юкка үлән йолкып йөрсәң, кулың корыр.**

**— Сыерчыкларга оя яса, эшең уңар.**

**— Баканы үтермә, кайгыдан башың чыкмас.**

**— Кош йомыркаларын ватма, күз яшеңне түгәрсең.**

**— Хайваннарны кыерсытма, үзеңә килер.**

Яки минә **бала кунакта.** Бу вакытта аңа мондый киңәшләр бирелә:

**— Ашарга өйрәнмичә ашка барма.**

**— Алдыңа куйган ашны хурлама.**

**— Алдыңа куйганны тавышсыз-тынсыз аша.**

**— Кунак теләгәнен түгел, күргәнен ашар.**

**— Ишек ачык булса да, сорап кер.**

**— Кунак туймаса да рәхмәт әйтер.**

**— Әдәпле кунак китәр вакытын үзе белер.**

**— Өч көн кунак бул, өч көннән соң ерак бул.**

**— Кунакның беренче көне — алтын, икенче көне — көмеш, өченче көне — бакыр, дүртенче көне — такыр.**

Мондый кисәтүләр, кыска гына итеп әйтелсәләр дә, тирән мәгънәгә ия. Мәсәлән, «Урманга шырпы белән бармыйлар» диелә икән, әеңнән чыкканда ук урманга карата яхшы ниятте булып юлга чыгарга кирәк. Шырпы алып, учак яндырып йөрергә чамалыйсың икән, янгын чыгуы, үзеңә генә түгел, йөзләгән кешеләргә зарар ки-

лүе бар, никадәр агач (ягулык, төзү материалы, матурлык, муллык), җиләк-җимеш, тирә-юньдәге чәчүлек җирләре әрәм булачак — менә шулар күздә тотыла. Шулай булгач, югарыда әйтелгән кисәтү — балада урманга, табигатькә карата сак мөнәсәбәт тәрбияләү чарасы ул.

Тәрбия белән бергә янәшә бер тоташ агым булып балага **зиһен сабагы** бирү дә бара. Ата-ана үз баласына (әби-бабай — оныгына) кышкы озын кичләрдә гарәп алфавиты өйрәткән. Гадәттә бу, эшләр бетеп бөтен йорт-җиргә тынычлык урнашкач үткәрелгән. Әти-әни, әби яки бабай балаларга үзе артыннан «әлеп», «би», «ти», «си», «җим», «хи», «дал», «зәл»... дип кабатлаткан. Кабатлый торгач, 3—4 яшьлек бала да алфавитны яттан әйтә алырлык дәрәҗәгә җиткән. Моннан соң догалардан, сүрәләрдән өзекләр ятлау китә. Хәтер, зиһен үсә, тел шомара, колак һәм күңел моң, аһәңлелек тоярга күнегә.

Гаилә мәктәбеннән бала мәктәп-мәдрәсәгә юл тота...

Яшь балага бөтен игътибарны туплау, тәрбия эшләрен аның туган минутыннан ук башлау һәм тәрбия чараларыннан иң отышлысын, нәни бала табигатенә иң яраклысын, баланың һәрьяклап үсешен тәэмин итәрлеген генә сайлап алу халык педагогикасының зирәклеге турында сөйли.

**(Дәвамы бар.)**

**Сания ИСМӘГЫЙЛЕВА,**
**Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА,**
**АДПИ доцентлары**

# Халык традицияләре

Яшь буынны тәрбияләүдә халык традицияләре гаять зур әһәмияткә ия. Әмма миңа тәрбиягә караган күп кенә фәнни хезмәтләр, диссертацияләр арасында яшь буынны милләт, халык традицияләрендә тәрбияләү турындагы тәплесен очратырга туры килмәде һәм моның бер «идеологик сере» бар: милләтче дип аталудан курку.

... Әнә шулай итеп, тоталитар система меңнәрчә еллар буена халык туплаган гәүһәрләрне — халык традицияләрен — бу бөек тәрбия хәзинәсен — файдалануны тыйды, ниндидер «уртак» тәрбия алымнарын файдалануны алга сөрде. «Ленин үрнәгендә...», «Коммунистик традицияләр үрнәгендә...», «Партия сәясәте яктылыгында...», «Комсомол, пионер, октябрят оешмалары традицияләрендә...» тәрбияләү кебек темаларга кандидатлык, докторлык диссертацияләре яклау киң колач алды. Педагогик журналларның «Коммунистик тәрбия» бүлекләре шул темаларга мәкаләләр бирү ярышына кушылдылар, дөресрәге, шуңа мәҗбүр ителделәр.

Кыскасы, тышкы яктан караганда, борчылырлык урын юк, барысы ал да гөл иде. Әмма укучылар торган саен тәртипсезләнә бардылар. Яшүсмерләр төркемнәре Казан кебек миллионлы шәһәрләрне курку-шөбһәдә тоттылар. Ата-ана үз баласыннан җәфа чикте һәм чигә.

Сәбәп нәрсәдә? Бу сорауга җавап бирү өлләни кыен түгел: балаларга дөрес тәрбия бирмәү, аларны өлкән буыннарның тәрбия традицияләреннән аеру.

Бөек педагогларның берсе К. Д. Ушинский (1824—1870) фикеренчә, һәр халыкның гасырлар буена туплаган тәрбия хәзинәсе — традицияләре бар, шулар нигезендә генә балаларга дөрес тәрбия бирергә мөмкин. (Җәя эчендә булса да әйтик: соңгы 40 ел эчендә аның хезмәтләре бөтенләй басылмады диярлек. Чөнки бөек галимнең тәрбиягә карашлары «бер милләт булдыру» вәсвәсәсенә туры килми иде. Ул иҗтимагый, тарихи үсеш һәм географик, табигый шартлар йогынтысында барлыкка килгән үзенчәлекләргә игътибар итә һәм шул мөмкинлекне тәрбия эшендә киң файдаланырга чакыра. Европа халыкларына, русларга нинди сыйфатлар хас икәнлеген тасвирлый, бары тик шуларга таянып кына, баланы тәрбияле итәргә мөмкин, ди.)

Татар халкының да искиткеч бай тарихы, тәрбия зиннәтләре бар. Шуларга ешрак мөрәҗәгать итү тәрбия эшенең нәтиҗәлелеген көчәйтер иде.

Революциягә кадәр татарларда эчү, ялганлашу, зина кылу, кеше җәберләү, урлашу кебек күңел өшеткеч күренешләр сирәк хәл иде. Сәбәбе — әлеге дә баягы — буыннан буынга килгән тәрбия ысулларын, чараларын, икенче төрле әйткәндә, халык традицияләрен файдалану.

«Нәрсә ул тәрбия?» дигән сорауга иң гади һәм һәркемгә аңлаешлы җавап мондый булыр иде кебек: Тәрбия — ул яшь, психологик, физик үзенчәлекләрне исәпкә алып, халыкның тәрбия традицияләренә нигезләнеп, балаларны һәрьяклы үсеш алган шәхес итеп формалаштыру. Чыннан да, без яшь буынны үзебезнең урынга әзерләргә, өлкәннәрдә булган иң күркәм сыйфатларны аларда тәрбияләргә омтылмыйбызмыни?

Иң беренче бурыч — балада үз милләтенә уңай караш, аның белән горурлану хисе тәрбияләү. (Үз халкын белмәгән кеше манкортка әверелә.)

**Үз милләте белән горурлану** һәр милләт кешесенә дә хас. Шул хис туган илгә, туган җиргә, аның тарихына, мәдәниятенә хөрмәт тәрбияләүгә юл ача. Патриотизм хисләре нигезендә әнә шулар ята. Кайберәүләр бик өстән уйлыйлар: янәсе, туган ил — ул бары тик Россия (элек: СССР), Татарстан исә туган ил түгел, алай әйтү милләтчелек була. Башкалабызга рәсми рәвештә килгән кунакларга республиканың партия җитәкчеләре: «Казан җиренә килүегез белән котлыйбыз!» — дип, мөрәҗәгать итәләр иде. Шулай итеп, адым саен татар кешесе күңелендәге «Туган ил» дигән төшенчәгә шөбһә салып тордылар. (Бүген халкыбызның 75 проценты чит җирләрдә яши — бу да шуның нәтиҗәсе түгелме икән?)

Татарстан — Туган илебез, безнең Ватаныбыз ул. Болай дип әйтү чынбарлыкка туры килә. Милләтчелек — ул үз милләтеңне генә сөеп, башкаларга кырын карау, аларны кимсетү. Бу исә безгә бөтенләй ят нәрсә.

Татарларга хас икенче бер традиция — **үз шәҗәрәңне, нәселеңне белү.** Моны без Каюм Насыйри, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Шиһап Мәрҗани һ. б. зыялыларыбыз әсәрләрендә ачык күрәбез. Шиһап Мәрҗанинең «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Бол-